СОВЕТ СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

24.10.2022 с.Соболевское № 28-134

Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Уставы белән,

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Соболевский авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 апрелендәге 47-197 номерлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына ( 2020 елның 21 декабрендәге 02-17 номерлы үзгәрешләр белән)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. びкararга 1нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге Советының
2022 елның 24» октябреннән
№ 28-134 карарына

1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге  җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет секретаре | 15904 |

1.2. Карарга 12нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский  авыл җирлеге Советының
2022 елның 24» октябреннән
№ 28-134 карарына
12 нче кушымта

Соболевский авыл җирлеге Башлыгының акчалата бүләкләре күләме

| Вазифа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 16389 |

2. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы                                        О. Н. Майорова